КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 24 гыйнвар г.Казань № 29

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 елда, җәмәгатьчелек фикер алышуларын яки ачык тыңлауларны үткәрмичә, генераль планнарга, җирдән файдалану һәм йортлар салу кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү очракларын билгеләү турында» 2023 ел, 28 гыйнвар, 63 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 елда, җәмәгатьчелек фикер алышуларын яки ачык тыңлауларны үткәрмичә, генераль планнарга, җирдән файдалану һәм йортлар салу кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү очракларын билгеләү турында» 2023 ел, 28 гыйнвар, 63 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «2023 елда» сүзләрен «2023 һәм 2024 елларда» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктның беренче абзацында «2023 елда» сүзләрен «2023 һәм 2024 елларда» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктның беренче абзацында «2023 елда» сүзләрен «2023 һәм 2024 елларда» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин